**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Березка, ул. Новостройка, 15А

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Новостройка ур., 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**19 ноябрь 2020 г.** **№ 11**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 26 нчы номерлы карары белән расланган Каенлык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Каенлык авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 26 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасын «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 6 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең урынбасары мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Гатауллин